РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ТЕРРИТОРИАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел. (факс): (84360) 2-14-34 16Т.048@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

Ленин ур., 46 нчы йорт, Teләче авылы, 422080
тел. (факс): (84360) 2-14-34 16Т.048@tatar.ru

# КАРАР

19 сентябрь 2022 ел № 15/5

**2022 елның 11 декабрендә Татарстан Республикасы Теләче районы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлаулар үткәргәндә участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләрен әзерләгәндә машина укый торган код белән технология куллану турында.**

Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 2017 елның 15 февралендәге 74/667-7 номерлы «Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләрен машинада укыла торган код технологиясе белән әзерләү һәм һәм машина укый торган кодтан файдаланып, Россия Федерациясенең «Сайлаулар» автоматлаштырылган системасына тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең әлеге беркетмәләрен тизләтелгән рәвештә кертү» карарының 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясе **карар итте**:

1. 2022 елның 11 декабрендә Татарстан Республикасы Теләче районы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлаулар үткәргәндә участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләрен әзерләгәндә машина укый торган код технологиясен куллану 2668 номерлы сайлау участогында башкарылачак дип расларга.
2. Әлеге карарны килештерүгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясе сайтында урнаштырырга.

Комиссия рәисе Р.Н. Яруллин

Комиссия секретаре А.В. Гыйниятуллина